КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 июль г.Казань № 472

Ачык территорияләрне дератизацияле һәм акарицидлы эшкәртү һәм анофелоген сулыкларны ларвицидлы эшкәртү үткәрүгә контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү методын куллану буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу тармагында контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының $20^1$ өлеше, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм йогышлы һәм паразит авырулар барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм сакланган ачык территорияләрне һәм сулыкларны профилактик эшкәртү үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын нәтиҗәле файдалану, әлеге эшкәртүләр үткәрелергә тиеш территорияләр һәм сулыклар мәйданнарын киңәйтү, республика территориясендә йогышлы һәм паразит авырулар йөртүче булып торган кимерүчеләр һәм бөҗәкләр санын киметү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Ачык территорияләрне дератизацияле һәм акарицидлы эшкәртү һәм анофелоген сулыкларны ларвицидлы эшкәртү үткәрүгә контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү методын куллану буенча методик тәкъдимнәрне (алга таба – Методик тәкъдимнәр) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар килеп чыгу һәм таралу өчен шартлар

булган һәм сакланган территорияләрдә һәм бүлмәләрдә лабораториядә тикшеренү ысулларны кулланып үткәрелә торган дезинфекцияләү, дезинсекцияләү һәм дератизацияләү үткәрү чараларын, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны гамәлгә ашыруны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыручы җирле үзидарә органнарына:

ачык территорияләрне дератизацияле һәм акарицидлы эшкәртү һәм анофелоген сулыкларны ларвицидлы эшкәртү үткәрүгә муниципаль контрактлар төзегәндә Методик тәкъдимнәргә таянып эш итәргә;

дератизацияле, акарицидлы һәм ларвицидлы профилактик эшкәртелергә тиешле территорияләр һәм сулыклар мәйданнарын Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе, аның территориаль бүлекләре белән килештереп билгеләргә (сатып алуларны планлаштыру этабында);

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең, аның территориаль бүлекләренең муниципаль контрактларны үтәү сыйфатын бәяләгәндә сыйфатсыз башкарылган профилактик эшкәртүләр фактлары турындагы мәгълүматларын исәпкә алырга.

3. Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә тәкъдим итәргә:

ел саен, зоогеографик куркынычларны һәм эпидемиологик хәлне исәпкә алып, дератизацияле, акарицидлы һәм ларвицидлы профилактик эшкәртелергә тиешле территорияләр һәм сулыклар мәйданнарын тәгаенләүне гамәлгә ашырырга;

дератизацияле, акарицидлы һәм ларвицидлы профилактик эшкәртелергә тиешле территорияләр һәм сулыклар мәйданнары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына җиткерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына сыйфатсыз башкарылган профилактик эшкәртүләр фактлары турында мәгълүмат бирергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы А.В.Песошин